ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2020 г. Заинск № 513

**«2021 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормаларын раслау турында»**

«Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пункты нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципапль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2021 елга түбәндәге кушымталарны расларга:

1.1. 2021 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары (1 кушымта);

1.2. Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә гомуми белем бирү оешмаларын, әлеге карарның 1 пунктында расланган махсус билгеләнгән автобусларда укучыларны мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп, финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән

укучыларның мәктәпләргә йөрүен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормаларын раслау турында» 2019 елның 21 октябрендәге 555 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.И. Захарова**

Л.Р. Печина
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «16» 11
513 номерлы карарына
1 кушымта

2021 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумда | автотранспорт чарасының бер километр юл үтүенә ставка, сумда |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «16» 11
513 номерлы карарына
2 кушымта

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба - муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чараларының саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта үткән юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактта үткән юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган эш хисап елында автотранспорт чарасының фактта үткән юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү
3.

3.1. i-муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта үткән юлы, километрда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру нормативы ставкасы, бер километрга, сумда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумда;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләре саны.